**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан,
Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул. Юбилейная, 1А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы,
Биектау районы,
Биектау авылы, Юбилей ур., 1А

тел./факс 8(84365) 74-779, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**01 апрель 2020 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**7 нче номер**

**Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 20 августында кабул ителгән 18 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 26 июль, ФЗ-227 нче Федераль законы нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР КЫЛА:**

1.Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 ел, 20 август, 18нче карары (2009 ел, 11 март, 49нчы карары редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктында:
а) 3нче абзацта «планлаштыру структурасы элементын (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементын» сүзләрен «урам-юл челтәре элементын һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда) " сүзләренә алмаштырырга);
б) 5нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;".

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырып халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

Җитәкче И.К.Мингазов